**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЯҢА УСЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫНЫҢ IV ЧАКЫРЫЛЫШ XXXXVIII УТЫРЫШЫ**

# КАРАР №78

**Яңа Усы авылы** **“06” сентябрь 2024 ел**

**Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында»гы 2018 елның “28” ноябрендәге 90 нчы номерлы Яңа Усы авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлегенә ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Яңа Усы авыл җирлеге Советы **КАРАР БИРДЕ:**

1. Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында»гы 2018 елның “28” ноябрендәге 90 нчы номерлы Яңа Усы авыл җирлеге Советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 пунктны түбәндәге эчтәлекле 1.1. пунктчасы белән тулыландырырга:
«1.1) Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мөлкәти мөнәсәбәтләр өлкәсендәге вәкаләтле органы тарафыннан билгеләнә торган исемлеккә кертелгән гомуми мәйданы 1000 квадрат метрдан артыграк булган административ-эшлекле үзәкләргә һәм сәүдә үзәкләренә (комплексларына) һәм алардагы урыннарга карата 1,2 процент.»;

1.2. Карарны түбәндәге эчтәлекле 3.3. пункты белән тулыландырырга:
«3.3. Әлеге карарның 2 пунктының 1.1. нче пунктчасы 31.12.2027 елга кадәр гамәлдә. ».

2. Әлеге карар Россия Федерациясе Салым кодексының 5 статьясы нигезендә үз көченә керә.

3. Карарны Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Яңа Усы авыл җирлегенең рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында түбәндәге адрес буенча халыкка җиткерергә: http://pravo.tatarstan.ru

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам

**Яңа Усы авыл җирлеге башлыгы:** **Г.С.Романова**